РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.07.2026 Буа шәһәре № 237 Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы «Чуар Тавык» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесенең эш режимын үзгәртү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон (25.04.2026 редакциясендә) нигезендә, мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны кимүгә бәйле рәвештә, бюджет акчаларын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы «Чуар Тавык» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе 12 сәгатьлек эш режимыннан 10,5 сәгатьлек эш режимына күчерелде (7.00 дән 17.30 га кадәр).

2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы «Чуар Тавык» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесенең җитәкчесенә учреждениенең оештыру һәм финанс документларына, штат расписаниесенә, локаль норматив актларына үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында https://buinsk.tatarstan.ru/) Интернет челтәрендә урнаштырылырга тиеш

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» мку башлыгына А.Н. Македонскаяга йөкләргә.

Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р. Шакирҗанов